СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д.53,
с. Ерыклы,423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы,423185

тел.,факс.:(8-84348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2020 елның 28 апреленнән № 84-137

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2015 елның 10 мартындагы 41-86 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы "Зирекле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы" на үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 40 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 228-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законның 13.1 статьясына , «Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 августындагы 283-ФЗ номерлы Федераль законга, «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында"гы 2019 елның 9 декабрендәге 98- ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына
түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Уставның "Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 5 статьясындагы 1 өлешендәге 17 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

17) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә»;

1.2. Уставның «Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре" 5 статьясындагы 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

"18) милләтара һәм конфессияара дуслыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм

үстерүгә, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру»;

1.3. Уставның «Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре" 5 статьясындагы 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 19 пункт өстәргә:

«19) халыкның массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итү»;

1.4. Уставның "Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре" 5 статьясындагы 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:

"20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү, яки аны рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары белән тәңгәлләштерү, капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү».

1.5. 6 статьяның 11 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

1.6. Уставның «Җирлек Советы депутаты статусы» 30 статьясындагы 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2), түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, профсоюз органы, шул исәптән җирле үзидарә органындагы сайланган беренчел профсоюз оешмасы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында түләүсез идарәдә итү, башка иҗтимагый оешманың съездында (конференциясендә), торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу (конференция) катнашудан тыш) катнашу (Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә алдан хәбәр итү шарты белән;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә яклау;

г) оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлекнең идарә органнарында һәм гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез яклау;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек,

әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, Попечительләр яки Күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә.

7.1. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләре 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, акча һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, бурычлар үтәлмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса.

7.2. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Президенты карары буенча Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

7.3. Әлеге статьяның 7.2 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, акча һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактларын ачыклаганда, Татарстан Республикасы Президенты депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату, яисә күрсәтелгән затларга карата тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка башка җаваплылык чарасын куллану турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

7.4. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес һәм тулы булмаган белешмәләр биргән депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим түгел икән, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль

берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органындагы вазыйфадан, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүдән мәхрүм итеп, аның вәкаләтләре вакыты беткәнче азат итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү, даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан аның вәкаләтләре вакыты беткәнчегә кадәр мәхрүм итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфаларны биләүне аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы тыю;

5) даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне вәкаләтләр срогы тәмамланганчы тыю.

7.5. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата әлеге статьяның 7.4 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.

7.6. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштырыла һәм (яки) муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә торган тәртиптә массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирелә.»

1.7. Уставның «Башкарма комитет вәкаләтләре" 50 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 10 пункт белән тулыландырырга:

"- Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә, үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү, яки аны рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары белән тәңгәлләштерү, капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итә».

1.8. Уставның «Башкарма комитет вәкаләтләре» 50 статьясындагы 1 өлешенең 7 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплану) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнаша;".

1.9. Уставның "Башкарма комитет вәкаләтләре» 50 статьясындагы 1 өлешенең 7 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- адресация объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары атамаларын бирү, мондый атамаларны үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адреслы реестрында мәгълүмат урнаштыру;».

2. "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының "Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен расларга. (1 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2015 елның 10 мартындагы 41-86 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы "Зирекле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы" на үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының карары проекты турында"гы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының әлеге карар проектын кабул итәргә һәм гавами тыңлауларга чыгарырга.

4. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2015 елның 10 мартындагы 41-86 номерлы карары белән расланган

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы "Зирекле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы" на үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының карары проекты турында"гы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының карар проекты буенча 2020 елның 13 маенда 10.00 сәгатьтә Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында Ленин ур., 53, Зирекле авылы, Яңа Чишмә районы, Татарстан Республикасы.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе, ачык тыңлаулар мәсьәләләре буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2006 елның 27 ноябрендәге 7-48 номерлы карары белән расланган, «Шешминская Новь» район газетасында 2006 елның 29 ноябрендәге 116 номерлы басылып чыккан Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советына ачык тыңлаулар үткәрүне, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының күрсәтелгән карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссия Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы карары проектын ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы утырышына кертергә тиеш.

7. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, "Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге Башлыгы

СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Д.Г. Гайфетдинов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге
Советы карарына Кушымта.
2020 елның 28 апреле, № 84-137

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының
«Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы»на
кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу Тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының» Зирекле авыл җирлеге» Уставына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәр 423185, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Зирекле авылы, Ленин урамы, 53, каб.№ 1 адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Советына язма рәвештә Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башкарма комитеты секретаренә тапшырыла.

Тәкъдимнәр «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырылган көннән алып, эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар 423185,Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Зирекле авылы, Ленин урамы, 53, каб. № 1 адресы буенча, яки почта аша (конвертында «Устав турында фикер алышу»тамгасы белән) җибәрелә.